**Китап - белем чишмәсе.**

Гимназиядә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын укылган китаплар буенча әдәби викториналар белән башладык. Уен барышында җиңүчеләр дә ачыкланды. 5б сыйныфында Фәнис Яруллинның "Табылдык сумка", "Алсу чәчәк" хикәяләрен иң яхшы укучы - Гарипов Кәрим, 6а сыйныфында Галимҗан Гыйльмановның "Язмышның туган көне" әсәрен бик әйбәт белүче- Петров Нияз, 7а сыйныфында Гадел Кутуйның "Рөстәм маҗаралары"н иң яхшы укучы - Габдрахманова Дилә, 8а сыйныфында Фәнис Яруллинның "Җилкәннәр җилдә сынала" әсәре буенча викторина җиңүчесе- Исрафилова Алия. Китаплар буенча укучылар бик матур фикерләрен әйттеләр, үзләренә ошаган геройлардан үрнәк алырга мөмкин икәнен аңладылар.

